**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2022 елның «23» августыннан № 235

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә шәһәр һәм шәһәр яны элемтәсендәге муниципаль маршрутларда пассажирлар һәм багаж ташуны гамәлгә ашыручы пассажирларга яңа коронавирус инфекциясенә каршы вакцинация узуны раслаучы персональ QR-кодлар, яңа коронавирус инфекциясенә каршы вакциналаштыруга медицина каршы күрсәткечләре булуны раслаучы гамәлдәге шәхси QR-кодлар булуын тикшерүне гамәлгә ашыручы хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүгә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2022 елның 22 мартындагы 82 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә даими пассажирлар йөртүне җайга салу һәм алар белән идарә итү системасын оештыру һәм камилләштерү, җәмәгать транспортында QR-кодлар кертүгә бәйле рәвештә, пассажирлар ташуны гамәлгә ашыручыларга алынмаган керемнәрен кайтару максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы, «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар һәм багажны даими йөртүне оештыру һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль законының 14 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы

территориясендә шәһәр һәм шәһәр яны элемтәсендәге муниципаль маршрутларда пассажирлар һәм багаж ташуны гамәлгә ашыручы пассажирларга яңа коронавирус инфекциясенә каршы вакцинация узуны раслаучы персональ QR-кодлар, яңа коронавирус инфекциясенә каршы вакциналаштыруга медицина каршы күрсәткечләре булуны раслаучы гамәлдәге шәхси QR-кодлар булуын тикшерүне гамәлгә ашыручы хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүгә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2022 елның 22 мартындагы 82 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5.1. пунктта «максатларын» сүзен «нәтиҗәләрен» сүзенә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына (икътисад буенча) йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов